ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.02.2019 № 176

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган объектлар (урыннар) исемлеген раслау турында" 2015 елның 19 июнендәге 684 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри рәвештә сакланырга тиешле кешеләр һәм объектларның (территорияләрнең) күпләп булу урыннарының террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннар һәм объектларның куркынычсызлык паспортларын формаларын раслау турында " 2015 елның 25 мартындагы 272 санлы Карары таләпләренә нигезләнеп, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган объектлар (урыннар) исемлеген раслау турында" 2015 елның 19 июнендәге 684 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган объектлар (урыннар) исемлеген кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган объектлар (урыннар) исемлеген раслау турында”гы 2018 елның 12 ноябрендә кабул ителгән 1589 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин